ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 17 Иске Урыссу ав. 12 сентябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге Советының 2021 елның 26 ноябрендәге 12 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 294-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге Советының 2021 елның 26 ноябрендәге 12 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2. Нигезләмәнең 4 маддәсенең 4.10.3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.10.3. Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248 - ФЗ санлы Федераль законның 57 маддәсендәге 1 өлешенең 3-6 бүлекләре һәм 66 мадәдәсендәге 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә тикшерү үткәрелгән очраклар керми.».

1.2. Нигезләмәнең 1 маддәсенең 1 бүлекнең 1.8 бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) планлаштыру структурасы элементлары (зоналар (массивлар), районнар (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), яр буе, гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бара торган территорияләр);».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча

урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Әминова